ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

___28.06.2019_____ г. Казань № ___77_____

Татарстан Республикасы Дәүләт торак төзелеше инцпекциясе карамагында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

1991 елның 27 декабрендәге «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 маддәсе нигезендә,

БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак төзелеше инспекциясе карамагында журналистларны аккредитацияләүнең тәкъдим ителгән Кагыйдәлен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны башлыкның беренче урынбасары И.Ф.Сафиуллинга билгеләргә.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак төзелеше
инспекциясенең 2019
елның «28» 06 2019
№__77__боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Дәүләт торак төзелеше инспекциясе карамагында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомум нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр 1991 елның 27 декабрендәге «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе карамагында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен (алга таба – аккредитация, Инспекция) регламентлый.

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе теләге белән аккредитация конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган срокка, яки аккредитацияләнгән журналистны вакытлыча булмаган очракта (вакытлы аккредитация) алыштыру өчен башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Аккредитациягә милек формасына һәм гамәлгә куючыларның составына, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чараларына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аны Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршындагы аккредитацияләүне раслау зарур.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитациягә гариза инспекциягә массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы белән, Инспекциянең күрсәтелгән гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, эш һәм кәрәзле телефоннар, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турындагы таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия

Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияне раслаучы документларның күчермәләре куела.

Вакытлы аккредитациягә гаризада шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, ә аккредитацияләнгән журналистны вакытлыча булмау сәбәпле алыштырган очракта - аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм алмаштыручы журналистны аккредитацияләү вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияне раслаучы документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация (аккредитациядән баш тарту турында карар инспекция башлыгы (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – башлык) тарафыннан гариза кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар тиешле боерык чыккан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә, редакция тарафыннан аны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Аккредитациядә массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда булган очракта (реклама тарату, эротик басмалар) баш тарта.

3.6. Гаризаларны карау, начальник боерыгы проектын әзерләү аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында, шулай ук редакциягә хәбәр итү кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чаралары Инспекциянең җаваплы заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәге хокукларга ия:

чарада катнашу;

чара турында Инспекция карамагында булган рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистика, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышу;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокукларга ия.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, чараның регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

пресс-релизларны, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм бүтән материалларны кулланганда, мәгълүмат чыганагына таянырга;

үзенең һөнәри эшчәнлеген гамәлгә ашырганда Инспекция эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.